**УТВЕРЖДЕНО**
Заведующим МБДОУ
Детский сад № 31 с.Новое Иглайкино
_______________ А.М.Маняпова
от 29.08. 2025

# Экологик тәрбия бирү буенча өлкән-мәктәпкә әзерлек төркемендә 2025-2026 уку елына перспектив план

**Бурыч:** Табигать турында гап-гади экологик күзаллау формалаштыру: хайваннар һәм үсемлекләр, тере организмның һәм тирәлекнең бердәмлеге, кеше һәм табигать бәйләнешләренең асылы турында; кешегә карата танып-белү кызыксынуы; әйләнә-тирәлекне саклауның мөһимлеген аңлау;
Уйлый,чагыштыра һәм исбатлый белү сәләтләрен үстерү;
Табигатькә карата аңлау һәм кайгыртучан караш тәрбияләү.

**Экологик тәрбия буенча план – программа.**
Балаларга тәрбия һәм белеем бирү төрле юнәлешләр буенча алып барыла. Аларның кайсысын гына алсак та, биктә мөһим һәм җидти өлкә. Шулар арасында экология тәрбияви яктан бик зур роль уйный. Балалар һәр көнне табигать белән тыгыз элемтәдә. Алар көндә кояш, күк йөзен, чирәм, кошлар һәм агачарны күрәләр. Кечкенәдән үк сабыйлар тере һәм тере булмаган табигать беләнк ызыксына башлыйлар. Куп кенә сораулар туа. Сорауларга җавап эзләгәндә, балалар интелектуаль,эмоциональ яктан үсәләр. Табигатькә карата сак караш, матурлыкны күрә белү балаларда миһербанлылык, кешелеклелек кебек сыйфатлар тәрбияли. Шундый сыйфатларга ия булган бала гына туган ягын ярата һәм аңа чын хуҗаларча карый беләчәк. Экологиядән тәрбия эшчәнлеген экскурсияләр, тәҗрибәләр, хезмәт, күзәтүләр, бердәм эшчәнлек аша тормышка ашырырга мөмкин. Балалалар экологиянең фәнни өлкә икәненә төшенергә, андагы үзгәрешләрне һәм бәйлелекне күрергә, кеше һәм табигатьнең аерылгысыз фактор, сәламәтлекнең төп чыганагы икәнен белергә, өйрәнеп калырга тиеш.
Балалар бакчасында табигать почмагының булуы зарур. Көндәлек күзәтү, үсемлекләр, тәҗрибә, күзәтү объектлары, табигый материаллардан ясалган кул эшләре, эш кораллары булырга тиеш.
Экологик тәрбия ике юнәлештә алып барыла:
1. Тере табигать:
-Үсемлек дөньясы;

-Хайваннар дөньясы.

-Күзәтүләр.

2.Тере булмагантабигать:

-Тере булмаган табигать турында белем бирү;

-Тәҗрибә– эксперементлар.

| Ай | Тема.<br>Программа эчтәлеге | Уртак эшчәнлек | Әти-әниләр белән эшләү |
|---|---|---|---|
| Сентябрь | Мөстәкыйль рәвештә һава торышын билгеләү. Аның үсемлекләргә, кошларга,җәнлекләргә йогынтысын әйтү( көчле җил агач яфракларын өзә, кошларга очу өчен кыен һ.б.) | Җәй турында әңгәмә.<br>Каен һәм чыршы агачын күзәтү<br>Халык сынамышлары белән танышу<br>Чәчәк орлыклары әзерләү | Әңгәмә-" Нәрсә ул экология һәм экологик куркынычсызлык"<br>Балалар белән өйдә экологик эш алып барылуын ачыклау максатыннан , анкета үткәрү |
| Октябрь | Участоктагы агачларны күзәтү.<br>Кайсы агачтан яфрак коелып беткән?<br>Җиргә пластмасса, пыяла һәм азык калдыклары күмеп кую.Тәҗрибә<br>Кошларны күзәтү( аларның җылы якка китүе) | Көз турында шигырьләр уку<br>Беренче суыкларны кырау төшүен күзәтү.<br>"Алтын көз" бәйрәмендә балалар чыгышы | Көзге табигатькә гаилә белән чыгу:<br>"Нинди матур син, көзге урман» |
| Ноябрь | Ноябрь көзнең соңгы ае. Көзге табигать, аның кошларга, хайваннарга тәэсире. | Әңгәмә:" Кояш нәрсәгә кирәк? Көннәр кыскара, төннәр озыная"<br>З.Гомәрова"Кояш елый" хикәясен уку<br>"Чыршы кызы турында | Консультация:<br>"Балалар белән чыгып йөреп кайту файдалы булсын өчен, дөрес урын сайлый беләсезме?" |
| Декабрь | Кышкы табигать | Мәрзия Фәйзуллина "Чыршының күлмәкләре" шигырен уку<br>Участоктагы кошларны күзәтү.<br>Җимлеккә азык салу.<br>Әңгәмә."Безнең якларда яшәүче кыргый хайваннар кышны ничек чыгалар?"<br>Дидактик уен "Җәнлекләргә чыршыны бизәргә булыш" | Кошлар турында кайгырту йөзеннән, җимлекләр элү, һәркөн кошлар ашату. |
| Гыйнвар | Кышкы агачларны күзәтү.<br>Кышкы табигатькә экскурсия .<br>Кызыл китап турында белемнәрен арттыру. | Әңгәмә<br>З.Гомәрова "Ашыгыч ярдәм" хикәя уку<br>Кар бөртекләре белән | "Без гаилә белән урманда ял итәбез" |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | тәҗрибәләр(аларны лупа аша карау)<br>"Кошларга ярдәм итик" Акциясендә катнашу. | |
| Февраль | Гөлләрнең тузаннарын сөртү<br>Суган һәм укроп утырту<br>Кышкы ашханә" картинасын карау. | Әкият уку "Кар малае" Сания Шәвәлиева<br>"Урман- күпкатлы йорт."- эшчәнлек | «Безнең гаиләдә чаңгы көне!» кышкы урманга экскурсия. |
| Март | Сунын үзлекләре һәм үсемлекләр тормышында әһәмияте- тәҗрибә уздыру | Кара каргаларны күзәтү.<br>Кыргый хайваннар язны ничек каршы алалар- әңгәмә.<br>Агач ботакларын алып кереп суга утырту һәм аларны күзәтү. | "Кече туганнарыбызны бик яратабыз"(йорт хайваннары , җәнлекләр, кошлар турында кайгырту) |
| Апрель | Эколята –безнең дусларыбыз.<br>Эколятлар белән танышу. | Әңгәмә "Табигатьнең булыышчылары –эколятлар"<br>Рәсемнәр карау.<br>Эколятлар битлеге ясау.<br>Мәйданчыктагы чүпләрне җыю. | Гаилә белән бергәләп йорт- җир тирәсен чүп-чардан арындыру.<br>Агач утырту" акциясендә катнашу |
| Май | "урман дуслары кагыйдәләре"<br>Табигатьтә үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре белән танышу. | Г.Лотфи"Тамчы"- хикәя уку<br>Ташлар белән тәҗрибәләр уздыру.<br>"Туфрак безне туендыручы"- эшчәнлек уздыру<br>Чәчәк түтәлләренә орлыклар чәчү | Консультация »Дару үләннәрен дөрес җыю һәм аларнын файдасы» |